КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 март г.Казань № 144

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм белем бирү өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 сентябрь, 640 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм белем бирү өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 сентябрь, 640 нчы карарына (2017 ел, 20 октябрь, 798 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы» дигән сүзләрдән соң «, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф системасында инновацияле инфраструктураны формалаштыру һәм аның эшләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 23 июль, 611 нче боерыгы белән расланган Мәгариф системасында инновацияле инфраструктураны формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе» дигән сүзләрне өстәргә;

әлеге карар белән расланган Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм белем бирү өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибендә:

2.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Оешманы инновация мәйданчыгы дип тану инновация проектын (программасын) тормышка ашыру чорында гамәлгә ашырыла. Төбәк инновация мәйданчыклары эшчәнлеге Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының төбәк инновация мәйданчыклары эшчәнлеген оештыру турындагы нигезләмә белән регламентлаштырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин